РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ ЮЛБАТСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422077, Республика Татарстан,
с. Юлбат, ул. Г.Тукая, 57
тел. (84362) 43-7-22

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮЛБАТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422077, Татарстан Республикасы,
Юлбат авылы, Г.Тукай урамы, 57 йорт
тел. (84362) 43-7-22

e-mail: Ulbat.Sab@tatar.ru


24.09.2018 № 21

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлегендә гражданнардан үзара салым акчасы җыю һәм аны куллану буенча җирле референдум билгеләү турында

“Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашу һәм сайлау хокукларының төп гарантияләре турында” 12.06.2002 №67-ФЗ Федераль законның 15 нче статьясына, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның төп принциплары турында” 06.10.2003 №131-ФЗ Федераль законның 22.56 статьялары, Татарстан Республикасының “Җирле референдум турында” 24.03.2004 №23-ЗРТ 18 статьясы, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясына туры китереп, Юлбат авыл җирлеге Советының 21.09.2018 № 20 “Референдум уздыру инициативасы турында” карары, Юлбат авыл җирлеге башкарма комитетының 21.09.2018 № 31 “Референдум уздыру инициативасы турында” карары нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлегендә гражданнардан үзара салым акчасы җыю соравын кертү буенча җирле референдумны 2018 елның 18 ноябренә билгеләргә.

2. Җирле референдумга куеласы сорауларны түбәндәгечә расларга:

“Сез яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Юлбат авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 2019 елда 300 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм аны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән ризамы:

– Юлбат авылында җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү;
– Тенеки авылында җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү;

– Йосыф-Алан авылында җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү.

ӘЙЕ ЮК”

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм җирлекнең мәгълүмат стендларында бастырырга.

4. Карар басылып чыккан (халыкка хәбәр ителгән) көннән соң үз көченә керә.

Юлбат авыл җирлеге башлыгы Т.Р. Шамсиев